**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.06.2016 Балык Бистәсе штп. № 87пи

2016 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Бәтке төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе каршындагы интернатта тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 17 декабрендәге 721 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1.2016 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Бәтке төп гомуми белем бирү мәктәбе "муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе каршындагы интернатта тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнар расларга

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Бәтке төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен финанслауны тәэмин итүне, гомуми белем бирү оешмаларының расланган норматив чыгымнары нигезендә, тәэмин итәргә тәкъдим итәргә:

- 2016 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында Һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында " 2015 елның 17 октябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;

- әлеге карарның 1 пункты белән.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 июнендәге 87 пи номерлы карары белән расланган

**2016 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Бәтке төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе каршындагы интернатта тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнары**

| Гомуми белем бирү оешмасының төре | Территориаль урнашуы | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
| --- | --- | --- |
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | Авыл җирлеге | 61372 |